ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.01.2021 г. Заинск № 45

**«Гражданнарга хезмәт урыны найм шартнамәләре буенча торак урыннар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 16 мартындагы 99 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, "Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында" 2007 елның 20 сентябрендәге 475 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына, "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында" 2012 елның 29 декабрендәге 2901 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Гражданнарга хезмәт урыны найм шартнамәләре буенча торак урыннар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 16 мартындагы 99 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. административ регламентка 2 кушымтаның “в” пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «гражданның күчемсез мөлкәт объектларына, шулай ук гаиләнең, балигъ булмаганнарны да кертеп, барлык гаилә әгъзаларына, тиешле муниципаль берәмлек территориясендә милек хокукы барлыгы (булмавы) турында белешмәләр булган дәүләт техник исәпкә алу һәм (яисә) техник инвентаризация буенча вәкаләтле оешманың белешмәсе»;

1.2. 5.8 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә».

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

С.А.Филюшина
7 07 75
Юрист